ГЛАВА
КУКЕЕВСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
РЫБНО-СЛОБОДСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

422669, Республика Татарстан,
Рыбно-Слободский район, Ноаая ул., дом 5,
с.Кукеево, 422669

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАЛЫК БИСТӘСЕ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
КҮКИ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШЛЫГЫ

422669,Татарстан Республикасы,
Балык Бистәсе районы, Яңа урамы, 5 нче йорт,
Күки , 422669

**Тел.: (8-4361)30581, факс: (8-4361) 30581, эл.адрес: Kuk.Rs@tatar.ru**


ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

. 2019 елның 18 октябре Күки авылы № 1

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Күки авыл җирлегенең Күки авыл торак пунктында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыены билгеләү турында

2003 елның 6 октябрендәге “Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында” 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 маддәләре, Татарстан Республикасының 2004 елның 28 июлендәге ”Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында” 45-ЗРТ номерлы Законының 35 маддәсе, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы “Күки авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге Уставының 22 маддәсе нигезендә КАРАР БИРӘМ:

1. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Күки авыл җирлегенең Күки авыл торак пунктында үзара салым кертү буенча гражданнар җыенының беренче этабын 2019 елның 30 октябренә билгеләргә.
2. Гражданнар җыены каравына куела торган сорауны расларга:

Сез 2020 елда Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Күки авыл җирлегенең Күки авыл торак пунктында тору урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешесеннән (уку йортларына йөреп укучы студентлардан гайре) 400 сум күләмендә үзара салым акчасы кертүгә һәм тупланган средстволарны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтеп түбәндәге эшләрне башкару өчен тотуга ризамы:

- Күки авылында Ленин , Б.Урманчы, Ю.Гагарин урамнарындагы юлларга вак таш җәю;
- Урам утлары лампалары сатып алу.
- кышкы чорда Күки авылы эчендәге юлларны кардан чистарту һәм тәртиптә тоту;

“ЯКЛЫЙМ” “КАРШЫ”

3. Әлеге карарны дәүләт теркәвеннән соң Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Күки авыл җирлегенең түбәндәге адрес буенча урнашкан махсус мәгълүмат стендында урнаштырырга: Күки авылы, Яңа урамы, 5

йорт һәм Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге “Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы”нда.

4. Карар басылып чыккан (халыкка белдерелгән) көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль районы
Күки авыл җирлеге башлыгы А.М.Бәдретдинов